ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 560-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 560-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2482-VI ДС

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектына
аңлатма язуы

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нормалары нигезендә кертелә.

2024 елның 4 аенда республика бюджеты үтәлешен исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен 23 712,0 млн.сумга арттыру тәкъдим ителә.

Оешмалар табышына салым буенча планлы билгеләнешне 5 000,0 млн. сумга арттырырга тәкъдим ителә. Үзгәрешләр машина төзелешендә, финанс эшчәнлегендә күтәрелгән керемнәр динамикасын һәм икътисадның аерым тармакларында күтәрелгән салым керемнәрен исәпкә алып кертелә.

Физик затларның керемнәренә салым буенча планлы билгеләнешне, асылда уртача хезмәт хакы үсүгә бәйле рәвештә кергән салымнан чыгып, 4 000,0 млн.сумга арттырырга тәкъдим ителә.

Салым булмаган керемнәр күләмен 14 712,0 млн.сумга арттырырга тәкъдим ителә. Үзгәрешләр банк депозитларында Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын урнаштырудан кергән керемнәр һәм матди һәм матди булмаган активларны сатудан күтәрелгән керемнәр фактын һәм динамикасын исәпкә алып кертелә.

«Кире кайтарылмый торган керемнәр» бүлеген федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар һәм башка керемнәр хисабына барлыгы 6 623,1 млн.сумга арттырырга тәкъдим ителә.

Керемнәр 18 юнәлеш буенча арта:

- Россия Федерациясе субъектлары милкендәге аэропорт комплексларында объектларны реконструкцияләүне гамәлгә ашыру - 3 750,0 млн. сум;

- «Менделеевск 2.0» муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү («ВЭБ.РФ» Дәүләт үсеш корпорациясеннән кире кайтарылмый торган керемнәр) – 430,0 млн. сум;

- төп гомуми белем бирү программаларын, мәктәпкәчә белем бирү программаларын, урта һөнәри белем бирү программаларын һәм өстәмә белем бирү

программаларыннан тыш, тормышка ашыручы мәгариф оешмаларын пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем бирү процессларын гамәлгә ашыру өчен җиһазлар белән тәэмин итү – 244,1 млн. сум;

- дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен, урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү органнарының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) – айлык акчалата бүләкләү – 188,9 млн. сум;

- махсус хәрби операция үткәрү чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби хезмәткәрләренә Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарына буйсынучы медицина оешмалары тарафыннан махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү – 110,7 млн. сум;

- өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру – 100,1 млн. сум;

– «хроник вируслы гепатит С» диагнозы белән диспансер күзәтүендә булган кешеләрне амбулатор шартларда вирусларга каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру – 92,3 млн. сум;

- Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, әмма Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китәргә мәҗбүр булып, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә күпләп килгән һәм вакытлыча урнашу һәм туклану пунктларында яшәүче Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклandыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары тоткан чыгымнарны каплау – 70,2 млн. сум;

- даими яшәү урыныннан китәргә мәҗбүр булган Херсон шәһәре һәм Херсо-н өлкәсенең бер өлеше халкына социаль түләүләр бирү-33,4 млн. сум;

- шикәр чире белән авыручылар өчен төбәк эндокринология үзәкләрен һәм мәктәпләрен булдыру (үстерү) һәм җиһазландыру (тулыландыру) – 13,1 млн. сум;

- авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын (район үзәк хастаханәләре, район хастаханәләре, участок хастаханәләре) тулыландыру (яңадан җиһазландыру) шикәр чирен ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр чиреннән интегүчеләрнең хәлен контрольдә тоту өчен җиһазлар белән тшэмин ите бетерү (яңадан җиһазлау) – 11,4 млн. сум;

- «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм субсидия – 10,2 млн. сум;

– «Мактаулы донор» билгесе белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү – 10,2 млн. сум;

- авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү (Территорияләрне үстерү фонды акчалары) – 8,7 млн. сум;

- зур чыгымлы чирләрдән интегүчеләрне дәвалау өчен дару препаратлары белән тәэмин итү буенча оештыру чаралары – 8,6 млн. сум;

- үз структурасында медицина реабилитациясе буенча медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләре булган медицина оешмаларын медицина әйберләре белән тәэмин итү (тәэмин итеп бетерү һәм (яки) яңадан тәэмин итү) – 1,2 млн. сум;

- Советлар Союзы, Россия Федерациясе Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына (Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль иминият фондыннан кергән акчалар) ай саен акчалата түләүне гамәлгә ашыру- 95,1 мең сум;

- максатчан билгеләнешкә ия булып, алдагы елларда файдаланылмыйча калган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар калдыкларын кайтару – 1 724,6 млн. сум.

Бер үк вакытта 9 юнәлеш буенча бюджетара трансфертлар күләмен киметүне исәпкә алырга тәкъдим ителә:

- демографик фактор сәбәпле укучылар саны артуга бәйле рәвештә, гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру – 94,3 млн. сум;

- кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме – 20,7 млн. сум;

- Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру буенча чараларны гамәлгә ашыру – 34,6 млн. сум;

- Россия Федерациясе субъектларында торак төзелешен үстерү программаларын стимуллаштыру буенча чараларны гамәлгә ашыру – 18,4 млн. сум;

- мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр челтәрен үстерү – 10,6 млн. сум;

- төбәк һәм муниципаль музейларны реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау – 3,4 млн. сум;

- сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләүнең төбәк проектын гамәлгә ашыру – 2,5 млн. сум;

- төбәк һәм муниципаль театрларны реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау – 0,2 млн. сум;

- «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» объекты өчен мәйданнан тыш челтәрләр булдыру («ВЭБ.РФ» Дәүләт үсеш корпорациясеннән кире кайтарылмый торган керемнәр) – 0,1 мең сум.

Тулаем алганда, 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешен 30 335,1 млн.сумга арттыру тәкъдим ителә.

Моннан тыш түбәндәге юнәлешләр буенча, план чорында федераль бюджет акчалары буенча 2025 елда керемнәрдә һәм чыгымнарда – 105,4 млн. сумга, 2026 елда – 110,6 млн. сумга артуны чагылдырырга кирәк:

- «Хроник вируслы гепатит С" диагнозы белән диспансер күзәтүендә булган кешеләрне амбулатор шартларда вирусларга каршы дару препаратлары белән тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыруга, 2025 елда – 91,2 млн. сумга, 2026 елда 110,6 млн. сумга;

- «Менделеевск 2.0» муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү («ВЭБ.РФ» Дәүләт үсеш корпорациясеннән кире кайтрылмый торган акчалар) – 2025 елда 14,2 млн.сумга.

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетының чыгым өлешен 47 026,2 млн.сумга арттырырга тәкъдим ителә

Ачыкланырга һәм чагылдырырга тиеш:

- федераль бюджет, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды һәм дәүләт корпорациясенең максатчан акчалары – 4 992,4 млн. сумлык;

- «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы нигезендә 2023 елда дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле Татарстан Республикасы исеменнән товарлар җибәрүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән, әмма үтәлмәгән дәүләт контрактлары өчен түләүгә чыгымнар, 11 155,2 млн. сум, шул исәптән:

2023 ел ахырында алынган 8 282,4 млн. сумлык махсус казна кредитлары;

юл эшләре, социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь төзү һәм ремонтлау программалары, агымдагы чыгымнар буенча Татарстан Республикасы бюджеты – 2 712,8 млн. сум;

«ВЭБ.РФ» Дәүләт үсеш корпорациясеннән кире кайтарылмый торган акчалар – 160,0 млн. сум;

- «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын реконструкцияләү» объекты буенча эшләр башкару максатында чыгымнар – 10 847,8 млн. сум;

- яңа инвестицион проектларны гамәлгә ашырганда инфраструктура объектларын төзүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр – 3 893,9 млн. сум;

- «Казан» халыкара аэропортында перронны реконструкцияләү чыгымнары – 3 750,0 млн. сум (БРИКС-2024 илләре саммитына әзерлек кысаларында федераль бюджеттан финанслашу белән);

- 2024 елның 1 июленнән бюджет өлкәсе, дәүләт һәм муниципаль хезмәт хезмәткәрләренә хезмәт хакы артуга бәйле чыгымнар – 3 666,8 млн. сум;

- республика бюджет учреждениеләренең агымдагы чыгымнарын һәм кредитор бурычларын түләү, шул исәптән матди-техник җиһазландыру, социаль ярдәм чаралары күрсәтү – 3 887,1 млн. сум;

- социаль әһәмиятле, фәнни, мәдәни һәм спорт чараларын, төбәк проектларын үтормышка ашыруга чыгымнар – 3 159,3 млн. сум;

- «Татдортрансинвест» акционерлык җәмгыятенә автомобиль юлын реконструкцияләү һәм төзү проектларын гамәлгә ашыруга проект финанслау махсуслаштырылган җәмгыятеннән алынган заем шартнамәсе буенча йөкләмәләрне финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр – 1 233,7 млн. сум;

– югары технологияләр өлкәсендә индустриаль парклар һәм технопарклар инфраструктурасы объектларын булдыру буенча алдагы елларда башланган проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итү чыгымнары – 440,0 млн.сум.

Бюджетның чыгым өлешендә шулай ук бюджет акчаларын баш бүлүчеләр белән чыгымнарның бюджет классификациясе кодлары арасындагы ассигнованиеләрне яңадан бүлүне чагылдырырга тәкъдим ителә:

- социаль-мәдәни өлкә объектларына, инженерлык инфраструктурасына, юл эшләренә капиталь кертемнәр һәм капиталь ремонт программалары буенча тиешле норматив хокукый актлар буенча;

- Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә.

Татарстан Республикасы Дәүләт эчке займнар программасында тәкъдим ителә:

- 2024 елда «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын реконструкцияләү» проектын гамәлгә ашыру кысаларында «СОПФ Инфраструктурные облигацияләре» ЖЧЖнең «ДОМ.РФ» АЖ кече җәмгыяте «ТАТДОРТРАНСИНВЕСТ АЖга 20 елллык түләү срогы белән 12 700,0 млн.сумлык заем бирүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасына дәүләт гарантиясе бирү турындагы нигезләмәне күздә тотарга. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе күрсәтелгән заемны тәэмин итүгә 2024 елда төп бурыч һәм аннан файдаланган өчен процентлар суммасына 726,9 млн. сумга (гомуми суммасы 19 251,1 млн. сум тирәсе) бирелә;

- бюджет турында закон белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт бурычы параметрларын, планлаштырылган гарантия бирүне исәпкә алып, шулай ук 2023 ел ахырында федераль бюджет кредитлары буенча 7 882,5 млн.сум күләмендә бурычның исәптән чыгарылуын һәм 2023 елның декабрендә бирелгән 6 428,5 млн. сум күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт

гарантиясен исәпкә алып, «А-295 Йошкар-Оладан – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Казан шәһәре чигенә кадәр М-7 «Волга» Зленодольск автомобиль юлын төзү» проектын тормышка ашыру өчен, үзгәртергә

Әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, федераль бюджет кредитларын түләү күләмнәрен аныклау өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларына төзәтмәләр кертү тәкъдим ителә.

Күрсәтелгән тәкъдимнәр буенча Татарстан Республикасы бюджетының гомуми күләме фаразлана:

- 2024 елга керемнәр буенча 429 934,2 млн. сум, чыгымнар буенча – 446 625,3 млн. сум, кытлык 16 691,1 млн. сум тәшкил итәчәк;

- 2025 елга керемнәр буенча 403 697,6 млн. сум, чыгымнар буенча – 416 195,6 млн. сум, кытлык 12 498,0 млн. сум тәшкил итәчәк;

- 2026 елга керемнәр буенча 427 514,8 млн.сум, чыгымнар буенча – 446 386,5 млн. сум, кытлык 18 871,7 млн. сум тәшкил итәчәк.

Бюджет кытлыгы финанслау чыганаклары белән тәэмин ителгән.

Югарыда тәкъдим ителгән үзгәрешләр 1, 2, 7, 12, 13, 17 статьяларга. 1, 2, 21, 3, 6, 7, 8, 18, $19^1$, 21, 30, 43 кушымталарга төзәтмәләр кертүгә китерәчәк

Закон проектына кертелә торган барлык үзгәрешләр буенча чагыштыру таблицалары кушып бирелә.

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты 2024 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен 30 335 054,0 мең сумга артуны һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын 47 026 182,8 мең сумга артуны, 2025 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен 105 448,6 мең сумга артуны кимүне һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын 105 448,6 мең сумга артуны, 2026 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен 110 594,2 мең сумга артуны һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын 110 594,2 мең сумга артуны күздә тота. Бюджет кытлыгы 2024 елга 16 691 128,8 мең сумга арта һәм 16 691 128,8 мең сум тәшкил итәчәк, финанслау чыганаклары белән тәэмин ителгән. 2025 һәм 2026 еллар план чорында бюджет кытлыгы үзгәрми.

Шулай итеп, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 33 статьясы нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына закон проектында каралган Татарстан Республикасы бюджеты күрсәткечләре нисбәтләнгән.

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, гамәлдә булуы туктатып торылырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип тану, гамәлдә булуын туктатып тору, үзгәрешләр кертү турында яисә яңа Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын кабул итүне таләп итми.